# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге составына керүче Түбән Биш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**12.11.2020** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 15 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең Түбән Биш авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

-мөселман зиратын койма белән әйләндереп алу;

- янгын гидранты урнаштыру;

- янгын җиһазлары һәм инвентарь сатып алу;

-Пролетарская урамына балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру ;

- урам утларын ремонтлау.»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 234 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 129 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 121 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 8 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең Түбән Биш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең Түбән Биш авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

-мөселман зиратын койма белән әйләндереп алу;

- янгын гидранты урнаштыру;

- янгын җиһазлары һәм инвентарь сатып алу;

-Пролетарская урамына балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру ;

- урам утларын ремонтлау.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Биш авыл җирлеге башлыгы Д.В.Насертдинов